Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Ык Тамагы авылы халык җыены

**2021 нчеелның 16 нчы декабрендәге 1 нче номерлы КАРАРЫ**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге Ык Тамагы авылы гражданнарының җыены

карар итте:

1. 2022 елда Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Ык Тамагы авылы территориясенддә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән үзара салым акчаларын 700 сум күләмендә, ә I һәм II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышында катнашучыларга бер тапкыр түләүне киметеп 350 сум күләмендә кертергә.

2. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1. Вакташалу (китерү, тигезләү)
2. Кышкы чорда юлларны кардан чистарту.
3. Урамнарны яктырту

3. Халык җыены нәтиҗәләрен Ык Тамагы авылының мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында "Бәзәкә авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга www.mendeleevsk.tatar.ru

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Бәзәкә авылҗирлегебашлыгы И.И. Кашафетдинов